**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең Иске Маврино торак пунктында гражданнар җыены үткәрү нәтиҗәләре турында**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**16.11.2022** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 16 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең Иске Маврино торак пунктында теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2023 елда үзара салымны 500 (биш йөз) күләмендә билгеләргә һәм җыелган сумманы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы:
- балалар мәйданчыгын төзекләндерү.»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 154 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 81 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 70 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 11 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең Иске Маврино торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.
2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең Иске Маврино торак пунктында теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2023 елда үзара салымны 500 (биш йөз) күләмендә билгеләргә һәм җыелган сумманы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы:
   - балалар мәйданчыгын төзекләндерү.» сорауы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл

җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) кабул ителгән көннән 7 көн дәвамында (Иске Маврин авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Маврин авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Нургалеев